Хәбибҗанова, Л. "Галстукларны салабыз, кулга көрәк алабыз" / Л. Хәбибҗанова // Шәһри Чаллы. – 2025. – №24 (2 апрель). – Б. 1.

# «Галстукларны салабыз, кулга көрәк алабыз»

Лилия **Хәбибҗанова**



/ ФОТО: ШӘҺӘР ХАКИМИЯТЕНЕҢ МАТБУГАТ ХЕЗМӘТЕННӘН

**1 апрельдән Чаллыда язгы санитар чистарту һәм яшелләндерү икеайлыгы башланды. 31 майга кадәр урамнар, парклар, тукталыш павильоннары, гомумән, шәһәр территориясе тулысынча тәртипкә китерелергә тиеш. 19 апрель гомумшәһәр өмә көне дип игълан ителде. Әмма мэр бу көнне көтмәскә, җыештыруны тизләтергә чакырды.**

«Чисталык - ул зур хезмәт нәтиҗәсе. Шәһәрне чистарту - Чаллы, «КАМАЗ» төзүчеләрдән калган күркәм традиция. 9 Май бәйрәменә шәһәр ялт итеп торырга тиеш», - диде Наил Мәһдиев. Бу шәхси секторда яшәүчеләр һәм 16 бакчачылык ширкәте хуҗаларына да кагыла.

Шәһәрне чүпләүчеләр белән аерым сөйләшәчәкләр. Комсомол районының ике урынында һәм Сидоровкада санкцияләнмәгән чүплекләр табылган. Торак-коммуналь хуҗалыгы идарәсе башлыгы Руслан Вильданов әйтүенчә, мондый күренешләр су, һава, туфракны пычрата һәм аларны җыештыру өстәмә чыгымнар таләп итә.

«Чүплек ясаучыларны таптыгызмы?» - дип кызыксынды Наил Мәһдиев хуҗалык җитәкчеләреннән. Руслан Вильданов «юк» дип җавап кайтарды.

«Димәк, начар эзлисез. Урынга барырга кирәк. Галстукларыгызны салыгыз, сез зур җитәкчеләр. Шундый зур чүплек «авторларына» чыгарлык дәлилләр булмый калмас. Максатыбыз - чүплек ясаучыларны табу һәм чүп-чардан арындыруны таләп итү. Эш хәтта чыгымнарда да түгел, шәһәребезгә булган мөнәсәбәттә», - диде мэр.

Быел шәһәрдә 28 мең агач-куак утырту планлаштырыла. Эшләрнең күбесе көз көненә туры киләчәк. Яз көне 6200 төп утыртачаклар. Нигездә урам, проспектлар, йорт һәм предприятие яннарында.